**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында дәүләт финанс контроле мәсьәләләре буенча ведомствоара координация советы составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында дәүләт финанс контроле мәсьәләләре буенча ведомствоара координация советы турында» 2005 елның 21 июлендәге ПУ-298 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 15 ноябрендәге ПУ-479 номерлы, 2007 елның 3 октябрендәге ПУ-523 номерлы, 2008 елның 1 мартындагы ПУ-96 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-207 номерлы, 2010 елның 20 августындагы ПУ-544 номерлы, 2010 елның 13 декабрендәге ПУ-806 номерлы, 2011 елның 23 мартындагы ПУ-146 номерлы, 2012 елның 6 февралендәге ПУ-67 номерлы, 2012 елның 24 июлендәге ПУ-617 номерлы, 2012 елның 4 декабрендәге ПУ-1011 номерлы, 2013 елның 9 сентябрендәге ПУ-868 номерлы, 2014 елның 12 июнендәге ПУ-570 номерлы, 2014 елның 20 декабрендәге ПУ-1160 номерлы, 2015 елның 28 мартындагы ПУ-371 номерлы, 2016 елның 29 гыйнварындагы ПУ-60 номерлы, 2016 елның 3 мартындагы ПУ-223 номерлы, 2018 елның 24 декабрендәге ПУ-878 номерлы һәм 2019 елның 11 маендагы ПУ-272 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында дәүләт финанс контроле мәсьәләләре буенча ведомствоара координация советы (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан А.К. Хамаевны чыгарырга;

б) Совет составына Ф.Ә. Әгълиуллинны – Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрын кертергә;

в) Совет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

М.Һ. Галиевның – «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты әгъзасы (килешү буенча)»;

К.Ә. Нугаевның – «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын башкаручы** **А.В. Песошин**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2019 ел, 02 ноябрь
№ ПУ-667